**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Комарова, д.14, с.Шешминская Крепость, 423104

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ШЕШМИНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Комаров урамы, 14 йорты, Шешминка Крепосте авылы, 423104

тел./факс(84396) 2-36-54 email: Shesh.Cmn2@tatar.ru

№62 16.03.2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 февралендәге 58 номерлы «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында»гы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25 номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге Советының 2013 елның 15 февралендәге 58 номерлы «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне, чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәгән өчен җәзаларны куллану тәртибе турында»гы нигезләмәне раслау хакында» карарына (Советның 2018 елның 21 декабрендәге 122 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.3 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзтезмәсен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)» сүзтезмәсе белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Шешминка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе